Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе «Мамадыш шәһәре өченче номерлы урта гомуми белем мәктәбе"

| | | |
|---|---|---|
| "Каралды"<br>МБ җитәкчесе<br>________Кашапова З.Г.<br>Протокол № 1_<br>" 28" август 2023 ел | "Килешенде"<br>Укыту – тәрбия эшләре буенча директор урынбасары<br>__________Фархуллина Н.Ф.<br>Протокол № 1<br>" 31" август 2023ел | "Расланды"<br>Мәктәп директоры<br>________Мухаметзянов Ф.С<br>Приказ № 47<br>"31" август 2023 ел |

***югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Нәкыйпова Рузилә Фаил кызының***
***6 нчы сыйныф укучылары өчен***
***"Тел дигән дәрья бар"темасына***
***дәрестән тыш эшчәнлек программасы***

2023-2024 нче уку елы

Scanned with AnyScanner

Scanned with AnyScanner

**Өстәмә эшчәнлектә планлаштырылган нәтиҗәләр**

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

- халык акылы, тормыш яме, яшәү көче чыганагы булган халык педагогикасы турында мәгълүматлы булу;
- әсәрләрнең жанрын аера белү;
- халык җырларын, биюләре элементларын белү;
- сөйләмдә мәкаль-әйтемнәр кулланырга өйрәнү;
- халык уеннарын өйрәнү;
- төркемдә партнер белән эшли белү;
- баланың үз эшен бәяли белүе.

Эш барышында балаларының яшь үзенчәлекләренә туры килә торган төрләргә зуррак урын бирү күздә тотыла. Бу – уеннар , җырлар, милли кием элементлары белән танышу, рәсемнәрен ясау, табышмаклар өйрәнү, иҗат итү.

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре**

Гомуми белем бирү мәктәбен тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана**:

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
- текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
- «гаилә», «туган ил», «мәрхәмәтлелек» төшенчәләрен кабул итү, «башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык», «кеше кадерен белү» кебек хисләр формалашу.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Урта белем бирү баскычында телгә өйрәтү, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар, презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә; укучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

***Танып белү нәтиҗәләре:***

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**

- уку хезмәтендә үзенә максат куя, бурычларны билгели белү;

Scanned with AnyScanner

Scanned with AnyScanner

- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;

***Коммуникатив*** **нәтиҗәләр:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисселек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

## Дәрестән тыш эшчәнлекнең эчтәлеге

| № | Бүлекләр, темалар | Эчтәлек |
|---|---|---|
| 1. | **Халык педагогикасы** | Кереш дәрес. Халык педагогикасы турында төшенчә. Халык педагогикасының туп чыганаклары һәм үзенчәлекләре. Педагогика фәне классиклары. Халык педагогикасында тәрбия факторлары һәм методлары. Халык педагогикасында өйрәтү һәм тәрбия чаралары. |
| 2. | **Әдәпле-әхлаклы камил кеше тәрбияләү – татар халык педагогикасында төп мәсьәлә** | Милләтебезнең төп сыйфатлары. Халык педагогикасында буыннар бәйләнеше. Гаилә тәрбиясе. Гаилә ныклыгы турында халык педагогикасы. Бишек җырлары. Туган тел-бөек педагог. Туган телем-әнкәм теле. Ата-ана хакы. Ана педагогикасы. Аталар сүзе-акылның күзе. Изгелек вә гаделлек- кешенең җан азыгы. Халык педагогикасында яхшылык һәм яманлык. Әхлак тәрбиясе.Әхлаксызлык һәм рәхимсезлек заманы булу ихтималының халык педагогикасында кисәтелүе. Хезмәт тәрбиясе. Онытыла барган һөнәрләрне барлау. Татар халкында иң күркәм сыйфатлар. Татарлар-чиста, кунакчыл, мәгърифәтле халык. Аулак өйләр. |

Scanned with AnyScanner

Scanned with AnyScanner

| | | |
|---|---|---|
| 3. | **Җирнең нуры кояш, кеше нуры-гыйлем.** | Халык педагогикасында акыл хезмәте культурасы. Кеше тормышында гыйлемнең нуры. Акыл тәрбиясендә һәм белем бирүдә халык кулланган төп чаралар. Китап-галим-телсез мөгаллим. Туган төбәгебездән чыккан галимнәр. Якташ язучыларыбыз иҗаты. Туган ягыбызга багышланган китаплар. Аларны барлау һәм танышу. Акыл тәрбиясе буларак табышмаклар. Акыл тәрбиясе буларак әкиятләр. Акыл тәрбиясе буларак мәкальләр, әйтемнәр, сынамышлар. |
| 4. | **Халкымның күңел бизәкләре** | Милли бәйрәмнәр. Татар халык җырлары. Туган төбәгебезгә багышланган җырлар. Татар халкының бию элементлары һәм аларны өйрәнү. Татар халкының кул эшләре. Чигү, бәйләү. Татар халык орнаментлары. Милли ризыкларыбыз. Туган төбәгебездә аш-су осталары. Проектлар яклау. Йомгаклау дәресе. |

**Дәрестән тыш эшчәнлекне үткәрү формалары:** экскурсия, түгәрәк өстәл, диспут, викторина, танып-белү һәм рольле уеннар.

**Дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру төрләре:** иҗади эш, практик дәрес, эзләнү эше, проект, әңгәмә.

Scanned with AnyScanner

Scanned with AnyScanner